







## ТАТАР ХАЛКЫ ГИМНЫ

### *Туган тел*

***Габдулла Тукай сүзләре***

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

**“КЫЗЛАР ИЛЕ” ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ**

**Безнең адрес:** Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Мәскәү районы, Декабристлар урамы, 89 А.

**E-mail: kzlar_ile@mail.ru**

**Шеф-мөхәррир:**
Лилия Марс кызы ӘХМӘТҖАНОВА

**Баш мөхәррир:**
Рәмилә Гамил кызы ГАЗИЗУЛЛИНА

**РЕДКОЛЛЕГИЯ**
**Хәбәрчеләр:**
Зилә ХӘБИБУЛЛИНА
Алисә РӘХМӘТУЛЛИНА
АШИТ Илайда
**Чыгарылыш өчен җаваплы:**
“Нур” балалар оешмасы матбугат үзәге

*Зыялы кыз — ил күрке!*

# КЫЗЛАР ИЛЕ

Фатиха Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия газетасы

2012 елның февраль аеннан чыга

6 +

№5 (6)

1 чирек

## Бүгенге санда:

- ***«Безнекеләр» сәхифәсендә - актуаль фикерләр!*** *2-3 битләр*
- ***Остаздан - мастер-класс!*** *5 бит*
- ***“Нур” балалар оешмасы белән “Сәләт-Казан” клубы нәрсә турында хыяллана?*** *6-7 битләр*
- ***2017 елның иң яхшы класслары!*** *9-10 битләр*
- ***Илһамлы сәхифә*** *10-11 битләр*







*Бәхет өчен бәхетле*
*була белү шарт.*
*Туфан Миңнуллин*

# Горурланабыз!

***Әхмәтҗанова Лилия Марс кызы - гимназия директоры.***

**Туган җире:** Сарман районы
**Тормыш девизы:** Гел күтәренке кәеф булсын!
**“Татар” дигәндә нәрсә күз алдына килә?** Татар моңы, татар тарихы, татар гореф-гадәтләре күз алдыма килә.
**Гимназия аның өчен ул:** Ике бөек шәхес - Фатиха Аитова һәм Туфан Миңнуллин исемнәре белән мәртәбәле 12 нче гимназия - кызлар иле, булачак әниләр иле. Гимназия гаиләсе бердәм, дус, тату булырга тиеш!





***Каюмов Айнур Айрат улы - физик тәрбия укытучысы, “Безнең яңа укытучы” гранты иясе.***

**Туган җире:** Теләче районы Алан авылы
**Тормыш девизы:** Бер урында таптанып тормаска!
**“Татар” дигәндә нәрсә күз алдына килә?** Түбәтәйдән егет кеше… Бәлки үзем ир-ат булгангадыр))
**Гимназия аның өчен ул:** икенче эш урыным булып тора, бер ел эчендә үз эшемне, балаларны, бигрәк тә беренчедә укучы кызларны БИК яратып өлгердем!

***Чумарина Флера Абдулла кызы - гимназиянең беренче укытучысы.***

**Туган җире:** Казан шәһәре
**Тормыш девизы:** Алга! Бары тик алга!
**“Татар” дигәндә нәрсә күз алдына килә?** Казан шәһәре үзәгендәге Иске татар бистәсен күзаллыйм.
**Гимназия аның өчен ул:** беренче укучыларым, ярты гасырга сыенган укытучы тәҗрибәсе… Тормышымның үткәне һәм бүгенгесе гимназия белән бәйле.



***Фотолар гимназия архивыннан алынды.***



# Әй, көянтә, көянтә!





И-и, рәхәт тә соң инде җәй көннәрендә авылда ял итүләре! Ял дигәч тә, гел уйнап-көлеп, җырлап-биеп кенә дә йөреп булмый инде анда. Ялгыз әбиемнең әле идәнен юарга, ишегалдын себерергә, тавык-чебешләрен дә ашатырга вакыт табарга кирәк. Көн саен чишмәдән көянтә-чиләгеңне асып су алып кайту да минем өстә.

Шулай беркөнне зәңгәр көянтәмә әбиемнең хан заманыннан калган чәчәкле чиләкләрен элдем дә, тау астында челтерәп аккан чишмәгә киттем. Әбием артымнан: “Озак торма, йортта бер тамчы су юк!” - дип кычкырып калды. Кирәк бит, чишмәгә җитәрәк, дус-ишләрем очрап куймасыннмы! Мине чакырып, кул болгаулары булды, көянтә-чиләкләрем сукмак кырыена очты, ә үзем - кызлар янына. Күпме вакыт узгандыр - белмим, әбиемнең чишмә суын көтеп калуы кылт итеп исемә төште. Шунда ук көянтә-чиләкләремне эзләп таптым да, чишмәгә таба йөгердем. Ашыгып кына чәчәкле чиләкләрем белән чумырып сап-салкын су алдым да, кызу-кызу адымнар белән кайтыр юлга юнәлдем. Мин кайтып кергәндә әбиемнең йөзендә ризасызлыгы күзгә ташланып тора иде. Гадәтемчә, көянтәне ишегалды уртасына ыргыттым, сулы чиләкләрне үз урынына куеп, иптәш кызларым янына ашыктым. Күзгә ак-кара күренми. Тизрәк урамга уйнарга чыгу теләге шулкадәр көчле: мин зәңгәр көянтәм аркылы бер генә сикердем, шунда ук ябык капкага барып төртелдем. “Көянтә аркылы чыгарга ярамый, кызым”, - дигән кисәтүле тавыштан кинәт айнып киттем, - койрык чыга!” Мин эсселесуыклы булып киттем. Ничек инде шундый вак-төяк өчен койрык үсә ала?! Юк, минем бер дә койрыклы кыз буласым килми…

Вакыт-вакыт онытылып китсәм дә, “койрык чыга” дигән сүз күңелемне өтеп ала. Берничә көн шул урыннарны тикшереп тә тордым. Койрык үсмиме, янәсе. Җәйге матур кичләрнең берсендә чәй өстәле артында койрык турында соравыма әбием кет-кет көлә-көлә җавап биргәч кенә тынычландым.

Олылар зирәк халык шул алар. Әйтсәләр, өздереп әйтәләр. Шул көннән мин көянтәмне кая туры килсә, шунда ташлап йөрмәс булдым. Һәр нәрсәнең үз урыны. Ул җирдә түгел, югарыда эленеп торырга тиеш икән ләбаса!

**АШИТ Илайда,**
**8 нче сыйныф укучысы,**
**Ф.Яруллин исемендәге фәннигамәли конференциясе җиңүчесе.**

# Хыяллар безгә канат бирә!



Минемчә, һәр кешенең хыялы бар. Кемдер космоска очарга тели, кемдер дөньяны күбрәк белергә хыяллана. Тик нәрсә соң ул хыял? Хыял – ул могҗизага ышану. Мин дә бит хыялый кеше. Минем төп хыялым - сәхнәгә чыгу иде, һәм... бу хыял тормышка ашты.



Мин алты яшемнән үк җырлый башладым. Беренче вакытларда, сәхнәдә җырларга курка идем. Ә хәзер инде, сәхнә - ул минем өем һәм яраткан урыным. Мәктәптәге бер концерт та миннән башка үтми. Мин монарга бик шат. Бу - минем шәхси уңышым гына түгел. Әти-әниемнән һәм мөгаллимнәремнән башка мин бу уңышларга ирешә алмас идем. Алар мине бу юлга бастырып җибәрделәр, мине гел илһамландырып тордылар. Мин аларга чиксез рәхмәтле! Сезнең дә хыялларыгыз тормышка ашсын!



*Зилә ХӘБИБУЛЛИНА,*
*6 А сыйныфы укучысы.*

# Театр – тормыш көзгесе

Билетлар сатып алдык,
Без театрга бардык.
Зур тамаша карадык,
Бик күп нәрсә аңладык.

Әлдермештән Әлмәндәрне,
Барыбыз да яраттык.
Артистлар уйнап бетергәч,
Шау-гөр килеп, кул чаптык.
Нәкъ Әлмәндәр карт шикелле,
Минем бабам да шаян,
Күп шаярта, күп көлдерә,
Сүзләрен таба каян?

Әлмәндәр һәм бабам күк,
Шаяннар күп дөньяда.
Тормышта да бик рәхәт,
Шундый кешеләр булганда!

Театр - тормыш көзгесе,
Көзге дөрес күрсәтә.
Һәр мизгелнең кадерен белеп,
Шәп яшәргә өйрәтә!

***Җәмилә ҖӘЛИЛОВА,***
***4 А сыйныфы укучысы.***




*“ХӘЯТ” театр студиясе сине көтә!*

Һәр сишәмбе һәм пәнҗешәмбе театр дөньясына рәхим ит! Театр студиясе җитәкчесе: Татарстанның атказанган артисты *Алмаз Сабиржанов*!



# “Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән!”



***Мозаффарова Гадилә - 2017 елгы чыгарылыш укучысы, Казан дәүләт мәдәният институты студенты, Т.Г.Миңнуллин премиясе иясе.***

**Туган җире:** Казан шәһәре

**Тормыш девизы:** Артка борылып карама!

**“Татар” дигәндә нәрсә күз алдына килә?** Татар кызы.

**Гимназия аның өчен ул:** гаилә.





***Фәйрушина Илвина - 2017 елгы чыгарылыш укучысы, Казан дәүләт энергетика университеты студенты, Туфан Миңнуллин премиясе иясе.***

**Туган җире:** Казан шәһәре

**Тормыш девизы:** Тормышта булмастай нәрсәләр юк! Алга!

**“Татар” дигәндә нәрсә күз алдына килә?** Үз телебезне, милли гореф-гадәтләребезне белгән татар кешесе.

**Гимназия аның өчен ул**: чын тормыш мәктәбе! Монда мине чын КЕШЕ булырга өйрәттеләр. Гимназиямдә мин үземне таптым

***Сиражетдинова Ландыш - 2017 елгы чыгарылыш укучысы, КФУ студенты, Туфан Миңнуллин бәләзеге иясе.***

**Туган җире:** Балтач районы

**Тормыш девизы:** Язмыш синең тез астына китереп сукса - егылмас өчен якасына ябыш. Утларга салса - үзең аннан да көчлерәк ян, шул вакыт кызуын сизмәссең. Суларга ташласа - күбек булып өскә күтәрелмә - асылташ булып төпкә бат, ялтыравыкны күреп, чумып алырлар. Тузан итеп һавага күтәрсә - яңгыр тамчыларына кушылып, җиргә төш. Карурманнарда адаштырса - кояшка карап юл сайла. Ташлар белән бастырса - чишмәгә әверелеп, ирекке ургы. Җиргә күмсә - орлык шикелле тишеп чык. Җилкәнеңне җилләр екса - сөюеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатка ирешә ала. Түземлеләр генә бәхеткә лаек! (Фәнис Яруллин)

**“Татар” дигәндә нәрсә күз алдына килә?** Тыйнак кына итеп салган мәчете белән татар авылы күз алдына килә.

**Гимназия аның өчен ул:** мөстәкыйль тормышым башланган җир. Биредә мин тормышның төрле яклы булаалганын белдем.

# “Безнең класс—эх, шәп!” ФЕСТИВАЛЕ

Кемнәрдер “Күбәләкләр”, “Татар кызлары”, “Казан кызлары”, “Галәм”, “Елмайчыклар”, “Туфан варислары”, “Йолдызлар”, “Рух”... Безнең классны алсак, 6 А сыйныфы -“Дуслык”. Девизыбыз да килешеп тора: “Кояшка чәчәкләр тартылган кебек, яңа белемнәргә тартылабыз без”.

Бу уку елында гимназиядә яңа бәйрәмнәр, бәйгеләр, кызыклы Фестивальләр барлыкка килде. Шундый Фестивальләрнең беренчесе - “Безнең класс - эх, шәп!” Фестиваль-бәйгесе.

26, 27 октябрьдә гимназиянең Актлар залында 1-11 сыйныф укучыларының “Безнең класс - эх, шәп!” Фестивале гөрләде! Бу чарага һәр класс ай дәвамында әзерләнде. Бирерә укучылар үзләренең девизын, эмблемасын, җыр-биюен, сыйныф почмагын тәкъдим итте.

Дус, тату, бердәм сыйныфлар бәйрәме “Туган тел” җыры белән тәмамланды. Туган илебезнең яраткан гимназиябезнең горурлыгы булыйк!



# ГАИЛӘ ФЕСТИВАЛЕ

Гаилә… Нәрсә соң ул? Мин кечкенә чактан ук гаиләне бер генә якын күз алдына китергәнмен икән. Иң элек гаилә - ул әти-әни, энем Ислам. Гимназиягә укырга кергәч, минем монда да тагын бер гаиләм барлыкка килгәнне сизми дә калганмын. Бу гаилә - минем сыйныфым!

Укучы - укытучы - әти-әни... Әлеге бәйләнешне истә тотып, гимназиябез укытучылары нәтиҗәле эшләр алып бара. Гаилә Фестиваленың төп максаты - сыйныф гаиләләрен берләштерү, аларның татулык, бәхет серләрен ачу.

Гимназиянең һәр классы - үзе бер гаилә. Чарага әзерлек барышында 1-11 сыйныф гаиләләре үзләренең нәсел агачларын, гаилә альбомнарын тәкъдим итте. Бу эшләр “Бәхетле гаилә” күргәзмәсенә урнаштырылды.

Гаилә Фестиваленың алып баручысы буларак, шуны күрдем: сәхнәдә укучыларның сыйныф җитәкчесе, әти-әниләре, әби-бабайлары да чыгыш ясады. Менә бу - бербөтен гаилә!

Безнең гимназиябез дә зур, бердәм, тату бер гаилә. Һәм әлеге гаиләнең башында, безне бер җепкә тезеп, һәр класс гаиләсенең уңышы өчен сөенеп торучы, киләчәккә җитәкләп баручы директорыбыз – Лилия Марсовна тора! Сезгә ихластан Рәхмәт әйтәбез!

Киләчәктә үз нәселебез шәҗәрәләрен барлап, әби-бабаларыбыз белән аралашып торсак, буыннар чылбыры өзелмәс. Гаиләләребез тату һәм бәхетле булсын!



*Сәхифәне Зилә ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде.*



# КАЛФАКЛЫ, ЧУЛПЫЛЫ ТАТАР КЫЗЛАРЫ!

Кызым Нурияне чын татар кызы булып үссен дип, Фатиха Аитова исемендәге 12 нче гимназиягә укырга бирергә булдык. Бу гимназиядә уку безнең тормышыбызны шундый кызыклы итте. Сыйныфыбыз җитәкчесе Миңнехуҗина Рәсимә Мидхәт кызы балаларны гимназиядә үтә торган чараларга еш катнаштыра башлады. Алар әкренләп үзләрен сәхнәдә тотарга, матур сөйләргә өйрәнделәр. Укытучыбыз балаларда могҗизалы сәнгать дөньясына мәхәббәт уятты. Ул тәрбияләгән укучыларның табигый сәләтләре елдан-ел ачыла бара. Үткән ел алар гимназиябез сәхнәсендә генә чыгыш ясаган булса, быел район, шәһәр, Россия күләмендә үткән бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулады.

Сүземне тәмамлап, шуны әйтәсем килә: балаларыбыз бик сәләтле, бары тик аларның сәләтен вакытында уятырга гына кирәк. Безнең укытучыбыз нәкъ вакытында балаларга ышанды, иҗади башлангычларына илһам бирде.



Апрель ае - шигърият ае. Гимназиябез, бөек шагыйребез Габдулла Тукай туган айда, аңа багышланган чаралардан гөрләп торды. Шигырь бәйрәмендә күпме укучы кызларыбыз сәнгатьле итеп шигырьләр сөйләде. Безнең яраткан укытучыбыз Рәсимә Мидхәт кызы сыйныфта укучы кызлар белән бик кызыклы сәхнә күренеше әзерләде. Бу күренеш гимназиянең Гран-при бүләгенә лаек булды.

Мин ышанам, киләчәгебез якты булыр. Чөнки безнең гимназиябездә белемен, вакытын балаларга багышлаган чын укытучылар эшли. Сыйныфыбызның әти-әниләре исеменнән, аларның барысына да зур РӘХМӘТ!

***Илсөя ХӨСӘЕНОВА,***
***3 Б сыйныфы әти-әниләре комитеты әгъзасы.***



# “КЫЗЛАРЫБЫЗ - ГИМНАЗИЯ ГОРУРЛЫГЫ!”

Бала өчен иң зур терәк – әти-әни. Безнең әти-әниләребез хөкүмәт эшенә дә өлгерәләр, мәктәп белән дә һәрдаим элемтәдә торалар. Класс сәгатьләрендә кызыклы әңгәмәдәш, җәен-кышын табигать кочагына алып чыгучы әти-әниләребезгә бик рәхмәтлебез.

Татарстан мәктәпләрендә барган ата-аналар бәйгесендә катнашу безнең әти-әниләребезне




үзара тагын да якынайтты. 2017 елның 28 апрелендә алар укучылар белән бергә үз көчләрен сынап карадылар. Бәйгегә Ягъфәрова Мәликәнең әбисе Әкълимә ханым да килгән иде. Әти-әниләрнең тәрбия эшендәге алымнары, кичәнең эчтәлеге һәркемгә файдага булгандыр. Дөрес, бу ярыш. Монда кемдер җиңә, кемдер җиңелә, дигәндәй...

Шулай итеп, безнең 6 А сыйныфы (хәзер 7А), “Тату классның серләре - 2017” ата-аналар комитетлары республика бәйгесендә катнашып, “Призёр” исеменә лаек булды!

Безнең сыйныф кызлары турында аерым әйтергә кирәк. Сыйныфка бик сәләтле кызлар җыелган: кайсы скрипкада өздереп уйный, кайсы бии, кайсыдыр курай моңландыра. Латыйпова Зәйнәп, Сәгъдиева Диана, Гыйниятова Зәринә кебек кызлардан башка бер концерт та үтми: алар - җырчы сандугачлар. Нәҗмиева Лилия – сәнгатьле сүз остасы. Ягъфәрова Мәликә, Хәмидуллина Әлфинә - сыйныфның отличниклары. Хәйруллина Алсу – оста биюче, үз вазифаларына бик тә җаваплы караучы укучыбыз. Байтимерова Әминә, Каһирова Фирүзә, Харунова Регина, Садыйкова Фәрхинур – җиңелү белмәс спортсмен-нарыбыз. Иң оста рәсем ясаучы кем дисәгез, бу – ике Камилә. Класс чәчтарашы Гомәрова Алия ясаган прическалар теләсә нинди конкурста җиңәрлек! Гимназия музейлары гидлары - Габдрахманова Гүзәл, Аббязова Дания турында да белә килгән кунаклар: җиренә җиткереп, саф татар телендә кирәкле мәгълүматны алар җиткерә. Шәрипова Камилә, Аманаева Мәликә, Кадыйрова Алинә, Ганиева Диләрә дә ипташләреннән һич калышмыйлар. Кузнецова Юля – иң оста режиссер, фоторепортер. Безнең сыйныф кызлары – гимназия горурлыгы!



***Рузилә Тәлгать кызы ХУҖИНА,***
***7 А сыйныфы җитәкчесе.***



# ҮРЛӘР ЯУЛАГАНДА...

Мин укытучы һөнәрен салават күпере белән чагыштырам. Иң кызыклысы шунда: без салават күперенең җиде төсен генә күрәбез, калган меңнәрчә төсләр зәңгәр күк сере булып кала. Укытучы һөнәре дә меңнәрчә төсләрдән тора. Ул сузган салават күперенең бер очы халыкка, икенче очы туган җир туфрагына барып тоташа. Һәр сандугач үз сабагында гына җырлый ала дигән шикелле, укытучы да туган ил кочагында дәртләнеп, мавыгып, үз халкына хезмәт итә, туган җир туфрагына таза, саф орлыклар чәчә ала.



Казанда 1908 елда Риза Фәхретдиннең "Әдәбе тәгълим” (“Укыту кагыйдәләре”) китабы басылып чыга. “Укытучы нинди булырга тиеш?”- дигән сорауга Риза Фәхретдин моннан бер гасыр элек үк инде җавап биргән. Ул укытучыларга үзләре укыткан һәм тәрбияләгән шәкертләре хакында җавап бирүе җиңел булмавын искәртә. Аның фикеренчә, “алтын булачак бер шәкертне туфрак итеп җирдә калдырганы да, һәм туфрак булачак бер баланы алтын итә белгән укытучы да бар. Шуңа күрә кешеләргә гыйлем өйрәтүче, дөнья йөзендә үз вазифасын намус белән җиренә җиткерүче укытучыдан да файдалы һәм кирәкле кеше юктыр”, дигән фикерне халык күңеленә сеңдерә ул. Моңа өстәп шуны әйтәсем килә: үз эшеңнең остасы булырга теләү һәр укытучының тормыш девизы булырга тиеш.

Без, 21 гасыр укытучылары, традицион укыту һәм тәрбия алымнары белән генә хәзерге заман баласы күңеленә юл табып булмасын тирәнтен аңлыйбыз. Чөнки замана баласы мәгълүмат эчендә “кайный”. Аларга аеруча авыр. Аны инде “язылмаган чиста ак кәгазь бите” белән чагыштырып булмый. Димәк, безгә элеккеләрне саклап, аңа заманчалык өстәп белем бирергә өйрәнергә кирәк.

Икенче буын федераль дәүләт стандартының таләпләре буенча укытучы балаларның фикер эшчәнлеге белән идарә итүче дирижер вазифасын башкарырга тиеш. Димәк, минем укучыларым мәктәпне тәмамлаганда, “үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”. Бу яңа стандартта “эшлекле белем бирү” дип атала.

Югарыда әйтелгәннәрне күз алдында тотып, мин педагогик эшчәнлегемнең нигезен укучыларыма булган мөнәсәбәтемдә күрәм. Ул шәхесне формалаштыру гына түгел, ә бәлки аңа үз сәләтен күрсәтер өчен шартлар тудыру, таныпбелүнең шомарып беткән юлыннан китү түгел, ә бәлки, тар гына узып китә алмаслык сукмак юлында да чыгар юлны үзләреннән таптыру, тауга кулыннан тартып менгерү түгел, үзенә менәргә өйрәтү. Бу максатларны тормышка ашыру өчен, укучыларыма белем биргәндә - өйрәнәм, алар белән аралашканда - өйрәнәм, педагогик осталыгымны үстергәндә - өйрәнәм. Моның өчен бертуктаусыз эзләнәм, иҗат итәм, эшләп карыйм, хаталанам, аларны төзәтәм. Эшнең яңа формаларын табарга омтылам, чөнки дәресләремнең алдагыларыннан аерылып торуын телим. Укучыларымның шатлануын күреп сөенәм.

Без яратып куллана торган “педагогик осталык” сүзтезмәсендәге “осталык сүзен мин болайрак аңлыйм:

**О**-омтылыш (укытучының күп белергә омтылуы, шуңа укучыларын да өйрәтүе, тәрбия бирү процессында укучының белемгә сәләтен ачуы);

**С**-стратегия - укучылар коллективы белән идарә итү осталыгы (укучыны үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрү);

**Т**-технология (дәресләрдә укытучының, укучыны кызыксындыру өчен, заманча эш алымнарын куллануы: тәнкыйди фикерләү, иҗади үсеш, шәхескә якын килү технологияләре һәм башкалар);

**А**-активлык (рухи яктан камил, иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашырырга сәләтле, гомумкешелек кыйммәтләренә уңай карашлы укучы тәрбияләү);

**Л**-лидерлык, ягъни әйдәп бару сәләте. (Укытучының укучысын үз артыннан ияртә алуы, мавыктырып, уку һәм тәрбия процессына кертә алуы һәм шуңа укучыларын да өйрәтүе);

**Ы**-ышаныч (укучыларда үз-үзләренә ышаныч тәрбияләү, төрле ситуацияләрдән чыгу юлларына өйрәтү);

**К**-канәгать булу хисе (ирешелгән уңышларга сөенү, яңаларына юл яру, авыр хезмәтнең татлы җимешләрен күрә белү һәм бәяләү).

Ә хезмәтемә иң зур бәя минем өчен ниндидер дипломнар да, грамоталар да түгел. Әгәр дәресем ахырында укучыларымнан “Рәхмәт Сезгә!” дигән сүзне ишетәм икән, димәк, аларга минем дәресем ошаган, алар мине көткәннәр. Мин аларга кирәк!

**Гөлнур Зәкәрия кызы**
**НАСЫЙБУЛЛИНА,**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы.**

***Гимназиядә 2002 елдан - “Нур” балалар оешмасы, 2016 елдан “Сәләт-Казан” клубы эшләп килә. Эш юнәлешләре төрле булса да, максатларыбыз бердәм! Киләчәккә илтә торган... Иң мөһиме без куйган максатларыбызга ирешергә, теләкләребезне чынга ашырырга омтылабыз. Халык шагыйре, депутат Разил абый Вәлиев әйтмешли, йә дөньяны үзгәртәбез без бүген, йә булмаса үзебез үзгәрәбез! Бергә һәм бердәм булыйк!***

***Рәисә РӨСТӘМОВА,***
***“Нур” балалар оешмасы президенты.***

# Киләчәкне бергәләп төзик!



Нур... Минемчә, нур - ул кояшның елмаюы, кояшның баласы... Кояш булгач, кәеф тә күтәрелә, күңелгә рәхәт тә булып китә. Шуңа күрә, безнең “Нур” балалар оешмасының төп максаты да - балаларның һәрчак күтәренке кәефле, позитив рухлы булуларында!

Безнең оешманың яңа эмблемасына килгәндә, биредә татар халкының төп символы булган лалә чәчәге сурәтләнгән. Чәчәкнең таҗлары ал төстә, ягъни “Нур” балалар оешмасында кызлар гына буын яки кызлар гимназиясен аңлата. Әлеге эмблемабыз Тазиева Әдиләнең гаиләсе, аның дизайнер туганы ярдәмендә эшләнде. Рәхмәт аларга!

“Нур” балалар оешмасы Активы 21 укучыдан тора. Без төрле юнәлешләр буенча эш алып барабыз. Һәр юнәлешне аерым бер Комитет үз эченә ала. Менә алар: мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты, ЗОЖ комитеты, ММЧ комитеты, музейлар комплексын өйрәнү комитеты, хезмәт һәм ял комитеты, гимназия чараларын оештыру комитеты.

“Нур” балалар оешмасы район, шәһәр, республика күләмендә узучы чараларда катнаша: “Лидер года”, “Бала хокук даирәсендә - Ребенок в мире прав”, “Лидер XIX века”, РДШ Форумы, “Количество свечек зависит от тебя” акциясе, Казан шәһәренең нәни гражданнары Форумы... Бу конкурсларның барысында да гимназиябезнең балалар оешмасы исеменнән чыгыш ясадым, монда мин бик күп дуслар, фикердәшләр таптым. Хәзерге вакытта мин Мәскәү районы балалар оешмаларын берләштерүче “Лига” балалар ассоциациясе әгъзасы булып торам.

“Ел лидеры” бәйгесенә баргач, үземә бер нәрсәне сеңдереп куйдым: “Лидерами не рождаются, ими становятся”. Һәрнәрсәгә безне тормыш өйрәтә. “Нур” балалар оешмасы безгә төрле мөмкинлекләр ача. Дусларым, киләчәкне бергәләп төзик!

***Зилә ХӘБИБУЛЛИНА,***
***“Нур” оешмасы вице-президенты.***







## “Сәләт” – безнең йөрәкләрдә!

Сәләт Казан Клубы
12-нче гимназия

“Сәләт” - 1994 нче елда КФУ профессоры, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе Җәүдәт Сөләйманов нигез салган оешма. Аның максаты – яхшы укучы, сәләтле балаларны бергә җыеп, кызыклы дәресләр ярдәмендә аларның сәләтләрен үстерү. Хәзер Сәләтнең төрле темаларга эшләүче аланнары бар. Математика, телләр, компьютер технологияләре, спорт, иҗат, һөнәрчелек һәм башка юнәлешләр. Кайчандыр “Сәләт” Казан янында - Лаеш районында беренче тапкыр җыелган булса, хәзер Россиянең төрле шәһәрләрендә, хәтта чит илләрдә дә аланнар оештырыла.

Мин “Сәләт”кә беренче тапкыр 2016 елның җәй көне бардым. “Сәләт-Тел” аланы миңа бик ошады. Ул башка каникуллардан аерылып торган бик күңелле ял булды. Француз теле дәресләренә йөрдем, бу телне бик ошаттым. Киләчәктә ныклабрак өйрәнер идем. Бик күп яңа дуслар таптым. Кайтыр вакыт җиткәч, алардан аерылу бик күңелсез булды, барыбыз да еладык.

Берничә атнадан “Сәләт-Санак” аланына бару бәхетенә ирештем. Ул да бик кызыклы булып истә калды, 3D-моделирование буенча күп нәрсә өйрәндек. Кичке чараларның, ярышларның барысын да әйдәманнарыбыз бик күңелле итеп оештырдылар. Саубуллашыр вакыт җиткәч, бергәләп таң каршыладык.



Уку башлангач, “Сәләт”тәге әйдәманнарны, клуб җитәкчеләрен үзебезнең 12 нче гимназиядә күрү мине бик сөендерде. Ә “Сәләт” клубының бездә ачыласын ишеткәч, икеләтә сөендем. Җәйге каникулга кадәр әле тагын бик күп тапкыр “Сәләт” дөньясында күрешәчәкбез!

Киләсе елларда “Сәләт” аланнарында тагын катнашырга телим. Мәктәпне тәмамлагач, әйдәманнар мәктәбендә укып, кабат “Сәләт”кә барасым килә! “Сәләт” мәңгелеккә безнең йөрәкләргә кереп урнашты. Без - “Сәләт”тә! Мәңгегә!

***Алисә РӘХМӘТУЛЛИНА,***
***6 А сыйныфы укучысы,***
***“Сәләт-Казан” клубы әгъзасы.***



